КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 июнь г.Казань № 459

2019 елда халыкара спорт ярышларында күрсәтелгән югары казанышлар өчен спортчылар һәм тренерларга дәүләт ярдәме турында

Халыкара спорт ярышларында катнашуга әзерлек чорында Татарстан Республикасы спортчыларына һәм тренерларына дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында, шулай ук, Россия Федерациясе территориясенә яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) үтеп керүне кисәтүгә бәйле рәвештә, 2020 елда рәсми халыкара спорт ярышларын бетерү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

халыкара спорт ярышларында югары спорт казанышлары өчен Татарстан Республикасының әйдәп баручы спортчыларына ай саен түләнә торган стипендияләр күләмнәре;

халыкара спорт ярышларында югары спорт нәтиҗәләре күрсәткән спортчылар әзерләгән өчен Татарстан Республикасы тренерларына ай саен өстәмә түләү күләмнәре.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2021 елда әйдәп баручы спортчыларга ай саен түләнә торган стипендияләр һәм тренерларга айлык өстәмә түләүләр 2019 елда рәсми халыкара спорт ярышларында күрсәтелгән нәтиҗәләр өчен башкарыла;

әлеге карар нигезендә айлык стипендияләр һәм айлык өстәмә түләүләр алучы спортчылар һәм тренерлар ай саен түләнә торган стипендияләр алуга дәгъва кылырга һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкара һәм бөтенроссия спорт ярышларында югары казанышлар өчен спортчылар һәм тренерларга дәүләт

ярдәме турында» 2018 ел, 20 февраль, 98 нче карары нигезендә өстәмә түләү алырга хокуклы түгел;

әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына 2021 елга билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла;

әлеге карар 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була;

әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 15 июнь, 459 нчы
карары белән расланды

Халыкара спорт ярышларында югары спорт казанышлары өчен Татарстан Республикасының әйдәп баручы спортчыларына ай саен түләнә торган стипендияләр күләмнәре

| Ярышлар исеме | Айлык стипендияләр, сум | | |
|---|---|---|---|
| | I урын | II урын | III урын |
| Дөнья чемпионаты | 60 000 | 50 000 | 40 000 |
| Европа чемпионаты | 50 000 | 40 000 | 30 000 |
| Дөнья беренчелеге | 30 000 | 25 000 | 20 000 |
| Европа беренчелеге | 25 000 | 20 000 | 15 000 |

Искәрмәләр:

1. Халыкара спорт ярышларында призлы урыннар алган, Россия Федерациясе Спорт министрлыгының төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чараларының һәм спорт чараларының бердәм календарь планына кертелгән спортчыларга ай саен түләнә торган стипендияләр:

олимпия булмаган спорт төрләре буенча - расланган стипендияләрнең 25 проценты күләмендә;

Олимпия, Паралимпия һәм Сурдлимпия спорт төрләре буенча Олимпия, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары программаларына кермәгән олимпия, паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары дисциплиналары буенча - расланган стипендияләр күләменең 50 проценты күләмендә.

2. Айлык стипендияләр 2019 календарь ел йомгаклары буенча спортчы тарафыннан күрсәтелгән иң югары нәтиҗә өчен 2021 календарь ел дәвамында түләнә.

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 15 июнь, 459 нчы
карары белән расланды

Халыкара спорт ярышларында югары спорт нәтиҗәләре күрсәткән спортчылар әзерләгән өчен Татарстан Республикасы тренерларына ай саен өстәмә түләү күләмнәре

| Ярышлар исеме | Өстәмә түләү күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | I урын | II урын | III урын |
| Дөнья чемпионатлары | 10 000 | 9 000 | 8 000 |
| Европа чемпионатлары | 7 000 | 6 000 | 5 000 |

Искәрмәләр:

1. Тренерларга айлык өстәмә түләүләр 2021 календарь ел дәвамында башкарыла һәм 2019 календарь ел нәтиҗәләре буенча ярышлар программасының бер төрендә шәхси дисциплиналарда күрсәтелгән иң югары нәтиҗә өчен билгеләнә.

Төркем дисциплиналарында һәм команда спорт төрләрендә һәр алдагы спортчы (төркем яки команда) өчен билгеләнгән зурлыкның 10 проценты күләмендә өстәмә түләү башкарыла.

2. Олимпия, Паралимпия һәм сурдлимпия спорт төрләре дисциплиналары буенча Олимпия, Паралимпия, Сурдлимпия уеннары программаларына кермәгән олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия спорт төрләре буенча түләүләр билгеләнгән күләмнең 75 проценты күләмендә башкарыла.

3. Олимпия, Паралимпия һәм Сурдлимпия уеннары программасына кермәгән спорт төрләре буенча түләүләр билгеләнгән күләмнең 50 проценты күләмендә башкарыла.

_______________________________